| СОВЕТ КУЗЕМБЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХУҖӘМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**25 октябрь 2023 ел** **№ 18**

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлегенең Бакчасарай торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына нигезләнеп, 2023 елның 25 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:«2024 елда Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлеге Бакчасарай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан; Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш,  Россия армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Бакчасарай торак пунктында су манарасына тирән насос, насос өчен бикләгеч сатып алу.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 54 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 30 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 30 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

"КАРШЫ" позициясе өчен тавыш бирде 0 җыенда катнашучылар.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Хуҗамәт авыл җирлегенең Бакчасарай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип таныргa.

Мәсьәлә буенча карар кабул ителде дип таныргa:«2024 елда Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлеге Бакчасарай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан; Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Россия армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Бакчасарай торак пунктында су манарасына тирән насос, насос өчен бикләгеч сатып алу.

Җыенның нәтиҗәләрен Хуҗәмәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (http://menzelinsk.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan) кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә бастырырга.

Әлеге карарны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен, җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Хуҗәмәт авыл җирлеге башлыгы ____________ Муртазина З.Р.
(имза)